КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 10 гыйнвар г.Казань № 1

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кабинет Министров Республики Татарстан ПОСТАНОВЛЯЕТ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарынан (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 138 нче; 2018 ел, 2 апрель, 200 нче; 2018 ел, 5 июнь, 425 нче; 2018 ел, 4 июль, 550 нче; 2018 ел, 8 декабрь, 1090 нчы; 2019 ел, 25 гыйнвар, 41 нче; 2019 ел, 28 февраль, 148 нче; 2019 ел, 26 апрель, 347 нче; 2019 ел, 29 апрель, 350 нче, 2019 ел, 28 август, 711 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

беренче абзацта «2020» саннарын «2022» саннарына алмаштырырга;

әлеге Карар белән расланган Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктның икенче абзацында «2016 елның 31 декабренә кадәр сайлап алынган» сүзләреннән соң «шулай ук 2010 елдан алдарак гамәлгә ашырыла башлаган һәм әлеге Тәртипнең 11.1 пункты нигезендә сайлап алу процедурасын узмаган инвестиция проектлары» сүзләрен өстәргә;

4 пунктның өченче абзацында "банкротлык" сүзен "аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның «ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) кредитлардан (займнардан) файдалануның суммар срогы әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә озынайтуны исәпкә алып әлеге пунктларда күрсәтелгән суммар сроклардан артмаган очракта,2017 елның 1 гыйнварыннан әлеге пунктның «а» – «е» пунктчаларында каралган юнәлешләр буенча, 2016 елның 31 декабренә кадәр сайлап алынган инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен алынган кредитларны (займнарны) рефинанслауга алынган кредитлар (заемнар) буенча, ә кредит (займ) суммасы рефинанслана торган кредит (займ) суммасына тигез, әгәр рефинанслана торган кредит (заем) заем тарафыннан тулы күләмдә үзләштерелмәгән яисә кредит (займ) суммасы түләнмәгән калдык суммасыннан артмаган булса, рефинанслана торган кредит (займ) буенча ссуда бурычы, әгәр рефинанслана торган кредит (заем) заемчы тарафыннан тулы күләмдә үзләштерелсә һәм мондый кредит (займ) төзү датасына билгеләнгән төп ставканың күләме Россия Федерациясе Үзәк банкының кредит шартнамәсен (займ шартнамәсен) беренчел төзү датасына гамәлдә булган рефинанслау ставкасы (хисап ставкасы) күләменнән артмый.»;

10 пунктның дүртенче абзацында «2019 елның 1 июленә торышы буенча» сүзләреннән соң «әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә алынган кредит (заем) буенча процентларны түләүгә заемчыга акча исәп-хисап бирелә торган чорга бәйсез рәвештә" сүзләрен өстәргә;

11 пунктның «б» пунктчасының дүртенче абзацында «банкротлык» сүзен "аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган» сүзләренә алмаштырырга;

11.1 пунктта:

«2019 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләреннән соң "2019 елның 1 гыйнварыннан соң әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы «ж" пунктчасында каралган кредитларны (займнарны) рефинанслауга алынган кредитлардан (займнардан) тыш" сүзләрен өстәргә;

«мондый проектлар белән" сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә" сүзләрен өстәргә;

12 пунктның «а» пунктчасындагы җиденче абзацта "үзйөрешле машиналар» сүзләреннән соң "яки транспорт чараларының, үзйөрешле машиналарның электрон паспортлары" сүзләрен өстәргә;

15 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык заемчыга кредитны (займны) максатчан куллануны раслый торган документларны, шулай ук субсидия бирү турындагы гаризада күрсәтелгән чорда кредит (заем) буенча процентларны түләүне раслый торган түләү йөкләмәләрен, шул исәптән алдагы ел өчен дә, берничә ай эчендә субсидия бирә.»;

Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле $15^1$ пункт өстәргә:

«$15^1$. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып кредитларны (займнарны) вакытында түләү тора.

Субсидия алучы Министрлыкка кредит (займ) түләү айыннан соң килүче айның 1 числосына кадәр субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә хисап бирә.»;

17 пунктта "шулай ук Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүенең вәкаләтле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча» сүзләрен «Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүенең вәкаләтле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешмәгән очракта," сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә кушымта өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин

Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

20__ елның ___________ торышы буенча
субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап

Субсидия алучы исеме: _________________________________

Вакыты: кредит (займ) түләү аеннан соң килүче айның 1 көненә кадәр бер тапкыр.

| Т/с | Нәтиҗә исеме | ГРҮБК буенча үлчәү берәмлеге * | | Нәтиҗәнең пландагы әһәмияте | Хисап датасына ирешелгән күрсәткеч |
|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | код | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

*ОКЕИ – Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы.

Субсидия алучы җитәкче
(вәкаләтле зат) _______________ _________ ______________________
(вазыйфа) (имза) (фамилиясе, исеме, әтисе исеме)

Үтәүче__________________ ________________________ ________________
(вазыйфа) (фамилиясе, исеме, әтисе исеме) (телефон)
Мөһер (булганда)

«__» ___________ 20__ ел

_______________________________________